ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
ПОСЕЛКА ГОРОДСКОГО ТИПА УРУССУ
ЮТАЗИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО
РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
423950, п.г.т. Уруссу, ул. Пушкина, 38

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЮТАЗЫ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
УРЫССУ ШӘҺӘР ТИБЫНДАГЫПОСЕЛОГЫ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ
423950, Урыссу шәһәр тибындагы поселогы
Пушкин урамы, 38

Тел.: 8(85593)2-42-17, e-mail: Pgt.Urussu@tatar.ru

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ**
« 01 » 06. 2023

**КАРАР**
№ 18

Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районының Урыссу шәһәр тибындагы поселогы Башкарма комитетының 2021 елның 30 апрелендәге 10 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районының «Урыссу шәһәр тибындагы поселогы» муниципаль берәмлегендә салым чыгымнары исемлеген формалаштыру һәм салым чыгымнарын бәяләү тәртибенә үзгәрешләр кертү турында

Россия Федерациясе Бюджет кодексының 1743 статьясы, «Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Россия Федерациясе субъектларының һәм муниципаль берәмлекләрнең салым чыгымнарын бәяләүгә гомуми таләпләр турында» 2019 елның 22 июнендәге 796 номерлы карары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы, «Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районының «Урыссу шәһәр тибындагы поселогы» муниципаль берәмлеге Уставы нигезендә, Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районының Урыссу шәһәр тибындагы поселогы Башкарма комитеты карар бирә:

Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районының Урыссу шәһәр тибындагы поселогы Башкарма комитетының 30.04.2021 ел, № 10 карары белән расланган Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районының «Урыссу шәһәр тибындагы поселогы» муниципаль берәмлегендә салым чыгымнары исемлеген формалаштыру һәм салым чыгымнарын бәяләү тәртибенә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. Тәртипнең 12 пунктындагы 2 абзацында «муниципаль программаларның структур элементларына» сүзләрен төшереп калдырырга;

1.2. Тәртипнең 12 пунктындагы 3 абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

"ташламалар алу хокукыннан файдаланган түләүчеләр саны һәм

ташламаны куллануга потенциаль хокукка ия булган түләүчеләр саны, яки 5 ел эчендә түләүчеләрнең гомуми саны нисбәте белән характерлана торган түләүчеләрнең ташламалар алуга ихтыяҗы.»;

1.3. Тәртипнең 3 пунктында «муниципаль программаларның структур элементларына» сүзләрен төшереп калдырырга.

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районының «Урыссу шәһәр тибындагы поселогы» муниципаль берәмлегенең мәгълүмат стендларында урнаштыру, Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат порталында «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә http://pravo.tatarstan.ru/ адресы буенча бастырып чыгару һәм Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы сайтында Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре Порталы составында «Рәсми Татарстан» дәүләт хакимияте һәм җирле үзидарә органнарының Бердәм Порталы составында «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә http://jutaza.tatarstan.ru/ адресы буенча урнаштыру юлы белән халыкка игълан итәргә.

3. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз җаваплылыгымда калдырам.

Җитәкче вазифаларын башкаручы А. Н. Захаров